СОВЕТ СТАРОАЙМАНОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423739, село Старое Айманово,
ул.Новая,

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ИСКЕ АЙМАН АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
423739, Иске Айман авылы, Яна
ур..,5А

Тел/факс (885552)5-01-63
Saym.Akt@yandex.ru

Исх. № 28

от «02» октября 2019 г.

# Карар

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы”Иске Айман авыл җирлеге” муниципаль берәмлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турындагы Федераль законга үзгәрешләр кертү турында” 2019 елның 1 маендагы 87-ФЗ номерлы Федераль Закон, “Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2018 елның 27 декабрендәге 498 санлы Федераль закон нигезендә Иске Айман авыл җирлеге Советы

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Айман авыл җирлеге Советының 24 июнь 2011 ел №5 санлы карары белән расланган “Иске Айман авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 7 статьяның 1 пунктындагы 13 пунктчасында "Күзәтүчесез хайваннарны аулау һәм карап тоту чаралары" сүзләрен " Хуҗасыз яшәүче хайваннар белән эш итү буенча эшчәнлек" сүзләренә алмаштырырга";

1.2. 25.1 статьяның 3 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- “6) авыл җирлегендә урнашкан торак пунктта, яңа төзелгән җирлек булдыру турында халык инициативасын тәкъдим итү максатларында, шулай ук яңа оешкан җирлектә, сайлау хокукына ия булган кешеләр саны 300 дән артмаган булса, яңа төзелгән җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасын билгеләү мәсьәләсе буенча;";

1.3. “Гражданнар җыены” 25.1 статьясына түбәндәге эчтәлекле 4 нче пункт өстәргә:

- “4. “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясында каралганча, гражданнар җыены, анда торак пункт яки җирлектә яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия яртысыннан артыграгы катнашканда вәкаләтле. Торак пунктта әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия яртысыннан артыгы бер үк вакытта булу мөмкинлеге булмаса, гражданнар җыены әлеге Устав нигезендә этаплап, гражданнар җыенын үткәрү турында карар кабул ителгән көннән алып бер айдан да артмаган вакыт эчендә үткәрелә, торак

пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә белән расланган тәртиптә гражданнар җыенын үткәрү Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Айман авыл җирлегендә уздырыла. Шул ук вакытта элек гражданнар җыенында катнашкан затлар тавыш бирүдә киләсе этапларда катнашмый”;

1.4. 32 статьяның 33 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.

3. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районы Иске Айман авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Иске Айман авыл
җирлеге Советы рәисе М.Р.Ахметханов